ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 5 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» 1993 елның 13 июлендәге 1934-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 19 июлендәге 89-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 6 – 7; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 10 (8); 2003, № 5; 2005, № 7 – 8; 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 1; 2011, № 11 (I өлеш); 2016, № 7 – 8) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1 статья. **Татарстан Республикасында ветеринария эше**

Әлеге Закон максатларында ветеринария эше дигәндә хайваннар авыруларын кисәтүне һәм аларны дәвалауны, яхшы сыйфатлы һәм ветеринария ягыннан куркынычсыз терлекчелек продуктларын чыгаруны һәм кеше һәм хайваннар өчен уртак булган авырулардан халыкны яклауны күз алдында тоткан фәнни белемнәр һәм гамәли эшчәнлек өлкәсе аңлашыла.»;

2) 3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3 статья. **Ветеринария эше өлкәсендәге белгечләр**

1. Югары яисә урта ветеринария белеме булган физик затлар ветеринария эше өлкәсендәге белгечләр була.
2. Ветеринария эше өлкәсендәге белгечләргә түбәндәгеләр керә:

Россия Федерациясе Дәүләт ветеринария хезмәте системасына керүче органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булып торучы ветеринария эше өлкәсендәге белгечләр;

Россия Федерациясе Дәүләт ветеринария хезмәте системасына керүче органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булып тормаучы ветеринария эше өлкәсендәге белгечләр.

3. Россия Федерациясе Дәүләт ветеринария хезмәте системасына керүче органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булып тормаучы, ветеринария эше өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария эше өлкәсендәге белгечләр Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендәге вәкаләтле органында теркәлергә тиеш.»;

3) 4 статьяның 1 өлешендә:

а) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Дәүләт ветеринария хезмәте системасына керүче органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булып тормаучы, ветеринария эше өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария эше өлкәсендәге белгечләрне теркәү;»;

б) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Дәүләт ветеринария хезмәте системасына керүче органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булып тормаучы, ветеринария эше өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария эше өлкәсендәге белгечләрнең эшчәнлеген тикшереп тору;»;

4) 5 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасында дәүләт ветеринария хезмәте системасына түбәндәгеләр керә:

- Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендәге вәкаләтле органы;
- Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендәге вәкаләтле органы буйсынуындагы ветеринария эше өлкәсендә лаборатория-диагностика тикшеренүләрен үткәрүче оешмалар;
- Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендәге вәкаләтле органы буйсынуындагы аның транспорт һәм матди-техник тәэминатын гамәлгә ашыручы оешма;
- Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендәге вәкаләтле органы буйсынуындагы районнарның һәм шәһәрләрнең дәүләт ветеринария берләшмәләре булып торучы оешмалар.»;

5) 6 статьяда:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) үз буйсынуындагы оешмалар эшчәнлегенә җитәкчелек итү;»;

б) 5 пунктта «республика программаларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын» сүзләренә алмаштырырга;

в) 7 пунктта «республика программаларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын» сүзләренә алмаштырырга;

г) 9 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

д) 10 пунктта «биологик» сүзе алдыннан «Татарстан Республикасы территориясендә эпизоотия һәм ветеринария-санитария иминлеген тәэмин итү,» сүзләрен өстәргә;

6) 9 статьяның исемендә «урындагы» сүзен «вазыйфаи» сүзенә алмаштырырга, «һәм дәүләт ветеринария хезмәте оешмаларының» сүзләрен төшереп калдырырга;

7) 12 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

8) 14 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14 статья. **Терлекчелек продуктларын җитештерү һәм саклау өчен билгеләнгән биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) планлаштыру һәм төзү**

1. Терлекчелек комплексларын, кош фабрикаларын, ит комбинатларын, терлекчелек продуктларын җитештерү һәм саклау өчен билгеләнгән башка биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны), крестьян (фермер) хуҗалыкларын һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларны планлаштырганда һәм төзегәндә хайваннар асрау һәм терлекчелек продуктларын җитештерү өчен, җитештерү калдыклары һәм хайваннарның йогышлы авыруларын китереп чыгаручылар белән әйләнә-тирә мохитнең пычрануын кисәтү өчен аеруча уңай шартлар тудыру каралырга тиеш.

2. Терлекчелек продуктларын җитештерү һәм саклау өчен билгеләнгән биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) төзүгә җир кишәрлеген бирү мондый биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) урнаштыруның гамәлдәге ветеринария нормаларына һәм кагыйдәләренә туры килүе турында дәүләт ветеринария күзәтчелеге органнарының бәяләмәләре булганда гына рөхсәт ителә.»;

9) 17 статьяның 5 өлешендә «терлекчелек калдыкларын» сүзләрен «биологик калдыкларны» сүзләренә алмаштырырга;

10) 18 статьяның 1 өлешендә:

а) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- Россия Федерациясе Дәүләт ветеринария хезмәте системасына керүче органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булып торучы ветеринария эше өлкәсендәге белгечләргә аларның таләбе буенча хайваннарны тикшерү өчен китерергә, шушы белгечләргә хайваннарның кинәт кенә үлүенең яисә аларның берьюлы күпләп авыруларының барлык очраклары турында, шулай ук аларның гадәти булмаган үз-үзләрен тотышлары хакында кичекмәстән хәбәр итәргә;»;

б) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- Россия Федерациясе Дәүләт ветеринария хезмәте системасына керүче органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булып торучы ветеринария эше

өлкәсендәге белгечләрнең хайваннарның авыруларын профилактикалау һәм шушы авыруларга каршы көрәш чараларын үткәрү турындагы күрсәтмәләрен үтәргә;»;

в) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- Россия Федерациясе Дәүләт ветеринария хезмәте системасына керүче органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булып торучы ветеринария эше өлкәсендәге белгечләр килгәнче, авыру ихтималы булган хайваннарны изоляцияләү чараларын күрергә.»;

11) 19 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19 статья. **Хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын юк иткәндә хайваннарны һәм (яисә) терлекчелек продуктларын тартып алу**

1. Хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын юк иткәндә дәүләт ветеринария инспекторлары булып торучы дәүләт ветеринария күзәтчелеге органнарының вазыйфаи затлары күрсәтмәләре буенча кабул ителә торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән хайваннар һәм (яисә) терлекчелек продуктлары, хайваннар һәм (яисә) терлекчелек продуктлары милекчесенә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән хайваннар һәм (яисә) терлекчелек продуктлары бәясе түләнеп һәм бу милекчегә хайваннарны һәм (яисә) терлекчелек продуктларын тартып алу турында тиешле документ бирелеп, тартып алынырга мөмкин.

2. Хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын юк иткәндә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары исемлеге һәм хайваннарны һәм (яисә) терлекчелек продуктларын тартып алу тәртибе Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.

3. Тартып алына торган мөлкәтнең бәясен билгеләүгә карата милекче судта шикаять белдерергә мөмкин.»;

12) 21 статьяда:

а) 2 өлештә «дәүләт ветеринария хезмәте органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендәге вәкаләтле органы» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә «дәүләт ветеринария хезмәте оешмалары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт ветеринария хезмәте системасына керүче оешмалар» сүзләренә, «дәүләт ветеринария учреждениеләрен» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт ветеринария хезмәте системасына керүче оешмаларны» сүзләренә алмаштырырга;

13) 22 статьяның 3 өлешендә «эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария белгечләрен» сүзләрен «ветеринария эше өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария эше өлкәсендәге белгечләрне» сүзләренә алмаштырырга;

14) 23 статьяның исемендә «Татарстан Республикасы дәүләт ветеринария хезмәте» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт ветеринария хезмәте системасына керүче оешмалар» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 21 июнь
№ 50-ТРЗ